Бишмунча авыл җирлеге чиге Тайсуган авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кама-Исмәгыйль участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 89 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка таба 550 м 89 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 89 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 200 м һәм көньяк-көнбатышка таба 450 м 88 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 550 м 88 нче, 94 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м, урман массивын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка

таба 300 м уза, 87 нче урман кварталы буйлап 400 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 600 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 200 м 87 нче урман кварталы буйлап, Кодаш – Кама-Исмагыйль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 450 м 87 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 87 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 74 нче урман кварталына кадәр бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 550 м әлеге урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м 74 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 600 м 74 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба, 300 м көньякка таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м 74 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 150 м 74 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 74 нче, 70 нче урман кварталларының көньяк, көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,1 км төньякка таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 250 м 70 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 100 м 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 300 м уза, төньяк-көнбатышка таба 200 м 72 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м 72 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 250 м һәм төньякка таба 250 м, урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап 50 м, төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап 30 м бара, шуннан соң 700 м 72 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бишмунча, Тайсуган һәм Яңа Нәдер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тайсуган авылыннан 2,5 км төньякта урнашкан 80 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бишмунча авыл җирлеге чиге Яңа Нәдер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 80 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, төньяк-көнчыгышка таба 200 м уза, аннары «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кама-Исмәгыйль участок урманчылыгындагы 71 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 800 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньякка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м 64 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 250 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м төньяк-көнбатышка таба 64 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньякка таба 700 м профильле автомобиль юлы буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 63 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Бишмунча, Яңа Нәдер һәм Кама-Исмәгыйль авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бишмунча авылыннан 3,8 км көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Бишмунча авыл җирлеге чиге Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 200 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кама-Исмәгыйль участок урманчылыгындагы 63 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 100 м 63 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап һәм 450 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 63 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 150 м, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, көньяк-көнчыгышка таба 150 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 350 м, көнчыгышка таба 150 м бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,2 км 66 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 66 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге

буйлап 300 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 400 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлык буйлап бара, аннары төньякка таба 150 м 138 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы башка инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 300 м аска таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м буа буйлап уза, инеш агымы буенча 100 м аска таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 400 м сазлык буйлап, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Әлмәт – Азнакай» – Бишмунча автомобиль юлына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 300 м әлеге автомобиль юлы буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының көньяк чиге буйлап, Кама елгасын кисеп үтеп, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 47 нче урман кварталына кадәр уза, шуннан соң әлеге урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 45 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 200 м уза, шуннан соң 45 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньяк-көнчыгышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м Түбән Мактама – Актүбә автомобиль юлына кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м әлеге автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 131 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, аннары, урман массивын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Мактама – Актүбә автомобиль юлына кадәр бара, 600 м әлеге автомобиль юлы буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м 46 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50 м сәнәгать объектының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м һәм көньяк-көнбатышка таба 200 м, Ирясь елгасын кисеп үтеп, 100 м көнчыгышка таба, 200 м 44 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 950 м 44 нче урман кварталының көньяк чиге буй-

лап уза, төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 44 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 44 нче урман кварталының һәм 131 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м бара, урман массивы буйлап 50 м 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлмәт муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
10 нчы кушымта

**Әлмәт муниципаль районының «Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Борискино авыл җирлеге Баграж-Никольский, Кузайкино, Яңа Троицкий, Сәрән, Ямаши авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы белән чиктәш.

Борискино авыл җирлеге чиге Зәй муниципаль районы белән чиктәш җирдә Борискино, Ямаши авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Красная Горка авылыннан 2,5 км көнчыгышта урнашкан 4 нче тоташу ноктасыннан алып Әлмәт муниципаль районы чиге буйлап Борискино, Кузайкино авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кузайкино авылыннан 2,9 км төньякта урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Борискино авыл җирлеге чиге Кузайкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып 600 м көньякка таба «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Ялан участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 1,2 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары,

Кичү елгасын кисеп үтеп, 500 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 350 м өскә таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 250 м плотинаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 30 м буаның уң яры буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 750 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м Кузайкино – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап Борискино, Кузайкино һәм Сәрән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Березовка поселогыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Борискино авыл җирлеге чиге Сәрән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 650 м Кузайкино – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 900 м әлеге автомобиль юлы буйлап уза, аннары көнбатышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 450 м «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ракашевский участок урманчылыгындагы 84 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м һәм көнбатышка таба 50 м бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м агач-куак полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,3 км

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Борискино, Сәрән һәм Баграж-Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Борискино авылыннан 2,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Борискино авыл җирлеге чиге Баграж-Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Борискино, Баграж-Никольский һәм Яңа Троицкий авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Борискино авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасыннан алып «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ракашевский участок урманчылыгындагы 64 нче, 65 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 400 м 65 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 2,3 км 65 нче, 66 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Борискино авыл җирлеге чиге Яңа Троицкий авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 54 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 800 м «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ракашевский участок урманчылыгындагы 59 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 400 м сәнәгать объектының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,5 км 46 нчы, 45 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, аннары 44 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк чиге буйлап 800 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 550 м 38 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 800 м әлеге урман кварталы буйлап аның көнбатыш чигенә кадәр бара, аннары 37 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк чиге буйлап 400 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Борискино, Яңа Троицкий һәм Ямаши авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Шөгерчә авылыннан 3,3 км көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Борискино авыл җирлеге чиге Ямаши авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буйлап, 300 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман

массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге инеш агымы буенча 2,8 км аска таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м буа буйлап, инеш агымы буенча 450 м аска таба Кичү елгасына кушылган җиргә кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 3,0 км өскә таба уза, аннары, яр буендагы урман полосасын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ямаши участок урманчылыгындагы 104 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 400 м 104 нче, 105 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 200 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м 105 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, көнчыгышка таба 250 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 900 м уза, 150 м 105 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м 105 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 650 м 105 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 750 м 105 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 700 м 103 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлмәт муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

## Әлмәт муниципаль районының «Бота авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Бота авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның соста-

выңдагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Бота авыл җирлеге Әлмәт, Аппак, Кузайкино, Рус Акташы авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы белән чиктәш.

Бота авыл җирлеге чиге Зәй муниципаль районы белән чиктәш җирдә Бота, Кузайкино авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бота авылыннан 3,7 км төньякта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Әлмәт муниципаль районы чиге буйлап Бота, Рус Акташы авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бота авылыннан 4,9 км төньяк-көнбатышта Мостай елгасында урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бота авыл җирлеге чиге Рус Акташы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып, Рус Акташы – Кузайкино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, инеш агымы буенча 1,1 км өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 50 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, инешне кисеп үтеп, 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бота, Рус Акташы һәм Әлмәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бота авылыннан 4,6 км көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бота авыл җирлеге чиге Әлмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бота, Әлмәт һәм Аппак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бота авылыннан 2,0 км көньякта урнашкан 13 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бота участок урманчылыгындагы 46 нчы, 47 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 500 м 47 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,4 км 47 нче, 51 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 500 м 52 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, төньякка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 750 м 52 нче, 53 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, аннары, Дербедешка елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, Дербедешка елгасын кабат кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 2,5 км 53 нче, 38 нче урман кварталларының көнбатыш, төньяк-көнбатыш, төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буй-

лап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешне кисеп үтеп, 500 м 35 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,1 км 35 нче урман кварталы буйлап, 450 м 35 нче, 34 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, инешне һәм ике тапкыр Дербедешка елгасын, текә ярны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньякка таба 1,2 км 34 нче, 28 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 28 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 17 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 350 м 17 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 1,4 км 17 нче, 16 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көнчыгышка таба 200 м 16 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, 50 м Рус Акташы – Кузайкино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 2,1 км 16 нчы, 18 нче урман кварталларының төньяк, төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнчыгышка таба 150 м 18 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 18 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сәнәгать объектының төньяк чиге буйлап, «Рус Акташы – Кузайкино» – Дербеден – «Казан – Оренбург» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,2 км 19 нчы, 20 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Бота авыл җирлеге чиге Аппак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бота, Аппак һәм Кузайкино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бота авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгында файдаланылмый торган җирләр буйлап, яр буендагы агач-куак полосасын кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бота елгасына кадәр уза, Бота елгасының текә сул ярын кисеп үтеп, аның агымы буенча 30 м өскә таба бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

«Казан – Оренбург» – Бота – Аппак автомобиль юлына кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 750 м әлеге автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 2,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бота авыл җирлеге чиге Кузайкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгында файдаланылмый торган җирләр буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Ялан участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м һәм көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м 82 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 81 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 700 м һәм төньяк-көнбатышка таба 750 м төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 81 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 81 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба, сынык сызык ясап, 1,1 км 81 нче, 79 нчы урман кварталларының төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 75 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 75 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, Рус Акташы – Кузайкино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м 75 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 3,3 км 75, 73, 69, 67 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман массивының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап уза, шуннан соң көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Әлмәт муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
12 нче кушымта

## Әлмәт муниципаль районының «Васильевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Васильевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Васильевка авыл җирлеге Югары Мактама, Миңлебай, Иске Суркино авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш.

Васильевка авыл җирлеге чиге Миңлебай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Васильевка, Миңлебай һәм Иске Суркино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Васильевка авылыннан 2,8 км көнбатышта урнашкан 67 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 50 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 84 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м 82 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 150 м 82 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 900 м 82 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 150 м 82 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 650 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км һәм көньяк-көнчыгышка таба 50 м Әлмәт – Лениногорск автомобиль юлына кадәр, Васильевка, Миңлебай һәм Югары Мактама авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Васильевка авылыннан 2,0 км төньякта урнашкан 69 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Васильевка авыл җирлеге чиге Югары Мактама авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 69 нчы тоташу ноктасыннан алып

көньяк-көнчыгышка таба 800 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырны, буаны, текә ярларны кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 450 м өскә таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 72 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 72 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 650 м 72 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м 72 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көнчыгышка таба 50 м 73 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 150 м 73 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 73 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 2,0 км 73, 74, 75 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 650 м 96 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м әлеге кварталның көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 191 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм көньякка таба 50 м, көньяк-көнчыгышка таба 150 м бара, шуннан соң көньякка таба 550 м 96 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 96 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 96 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 96 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба 350 м 103 нче, 106 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап бара, шуннан соң, Түбән Мактама – Иске Суркино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза,

аннары көньяк-көнчыгышка таба 450 м һәм көньяк-көнбатышка таба 300 м 106 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 106 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 111 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 111 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба һәм 200 м көнбатышка таба уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм көньякка таба 50 м бара, 350 м 111 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Васильевка, Югары Мактама авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Улаклы Чишмә авылыннан 300 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 70 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Васильевка авыл җирлеге чиге Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 70 нче тоташу ноктасыннан алып Әлмәт муниципаль районы чиге буйлап Васильевка, Иске Суркино авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Суркино авылыннан 2,7 км көнчыгышта урнашкан 68 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Васильевка авыл җирлеге чиге Иске Суркино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 68 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 200 м һәм көньяк-көнбатышка таба 150 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 150 нче урман кварталы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнбатышка таба 400 м, төньякка таба 400 м 150 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары төньякка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 250 м 150 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 129 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Әлмәт – Лениногорск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 129 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 100 м 128 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, инешне кисеп үтеп, 200 м 128 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 128 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,0 км, төньяк-көнчыгышка таба 150 м 128 нче, 127 нче урман квартал-

ларының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 300 м һәм, Түбән Мактама – Иске Суркино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 150 м уза, аннары көнбатышка таба 650 м, төньякка таба 500 м 127 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 800 м 127 нче, 94 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, 100 м сәнәгать объектының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, төньякка таба 250 м 94 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, 700 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Әлмәт – Лениногорск автомобиль юлына кадәр уза, аннары, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге автомобиль юлы буйлап көньяк-көнбатышка таба 600 м бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, 700 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 67 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Әлмәт муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>13 нче кушымта

**Әлмәт муниципаль районының «Югары Акташ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Югары Акташ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картасхемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Югары Акташ авыл җирлеге Әлмәт, Кәләй, Кичү, Урман-Кәләй, Рус Акташы һәм Ямаш авыл җирлекләре белән чиктәш.

Югары Акташ авыл җирлеге чиге Рус Акташы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Югары Акташ, Рус Акташы һәм Әлмәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дербеден авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 950 м «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бота участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 350 м 55 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 50 м көнбатышка таба уза, аннары 100 м 55 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м сәнәгать объектының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 800 м 55 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 700 м 65 нче, 57 нче урман кварталларының төньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, төньяк-көнбатышка таба 750 м 57 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км 57 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап һәм 56 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба 1,4 км 56 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,9 км 56 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 50 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 150 м аска таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м буа буйлап бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына һәм Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, инеш агымы буенча 2,8 км аска таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Одногулка елгасына кадәр бара, Чаллы – Зәй – Әлмәт автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге елга агымы буенча 2,3 км аска таба Югары Акташ, Рус Акташы һәм Ямаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Акташ станциясеннән 2,3 км төньяк-көнчыгышта Одногулка елгасында урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Акташ авыл җирлеге чиге Ямаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып Одногулка елгасы агымы буенча 350 м аска таба уза, аннары төньякка таба 50 м буа буйлап бара, Одногулка елгасы агымы буенча

850 м аска таба Дала Зәе елгасына кушылган җиргә кадәр бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге елга агымы буенча 6,5 км өскә таба уза, аннары Дала Зәе елгасы буенча 10 м төньяк-көнчыгышка таба уң ярына кадәр, сынык сызык ясап, 300 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Поташ Аланы участок урманчылыгындагы 171 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 200 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 250 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, күлне кисеп үтеп, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Югары Акташ, Ямаш һәм Кәләй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Нолинка авылыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Югары Акташ авыл җирлеге чиге Кәләй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 100 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Поташ Аланы участок урманчылыгындагы 172 нче урман кварталы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Дала Зәе елгасына кадәр уза, 10 м әлеге елга буйлап һәм аның агымы буенча 250 м өскә таба инеш белән кушылган җиргә кадәр бара, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге инеш агымы буенча 1,0 км өскә таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м буа буйлап бара, Чаллы — Зәй — Әлмәт автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, инеш агымы буенча 1,0 км өскә таба уза, аннары, яр буендагы агач-куак полосасын кисеп үтеп, көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньяк-көнбатышка таба 450 м сәнәгать объектының көньяк чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнбатышка таба, 1,0 км көньяк-көнбатышка

таба уза, 100 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м сәнәгать объекты буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 200 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 650 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м бара, аннары 100 м көньякка таба урман полосасының көнбатыш чиге буйлап Югары Акташ, Кәләй һәм Урман-Кәләй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кәләй тимер юл станциясе поселогыннан 700 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр бара, шуннан соң чик Югары Акташ, Кәләй һәм Урман-Кәләй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кәләй тимер юл станциясе поселогыннан 1,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 700 м, инешне һәм яр буендагы агач-куак полосасын кисеп үтеп, 450 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көнбатышка таба 400 м «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бота участок урманчылыгындагы 68 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 100 м сәнәгать объекты буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 68 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 200 м сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м 68 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Акташ Инеше елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 1,3 км аска таба Югары Акташ, Кәләй һәм Кичү авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сабанчы авылыннан 700 м көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Югары Акташ авыл җирлеге чиге Урман-Кәләй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 45 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м сәнәгать объектының көньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнчыгышка таба 700 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап уза, аннары төньякка таба 250 м профильле башка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, 250 м әлеге профильле автомобиль юлы буйлап һәм 250 м аңа бүлеп бирелгән

полосаның көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап 200 м төньякка таба, төньяк чиге буйлап 200 м көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньякка таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 200 м сәнәгать объектының төньяк чиге буйлап 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Акташ авыл җирлеге чиге Кичү авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып Акташ Инеше елгасы агымы буенча 650 м аска таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Әлмәт, Югары Акташ һәм Кичү авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сабанчы авылыннан 1,2 км көнбатышта урнашкан 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза

Югары Акташ авыл җирлеге чиге Әлмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бота участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 950 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км 55, 64, 73 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,5 км 73 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, 100 м сәнәгать объектының көньяк чиге буйлап, 750 м 73 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 650 м 73 нче, 74 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 74 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 300 м һәм көнбатышка таба 300 м, 88 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 1,9 км 88 нче, 90 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлмәт муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
14 нче кушымта

## Әлмәт муниципаль районының «Югары Мактама авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Югары Мактама авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Югары Мактама авыл җирлеге «Әлмәт шәһәре» һәм «Түбән Мактама шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре, Габдрахман, Васильевка, Колшәрип, Миңлебай, Яңа Нәдер, Тайсуган авыл җирлекләре, Бөгелмә һәм Лениногорск муниципаль районнары белән чиктәш.

Югары Мактама авыл җирлеге чиге Колшәрип авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Югары Мактама, Колшәрип һәм Миңлебай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Миңлебай авылыннан 1,7 км төньякта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,5 км Әлмәт — Чупай автомобиль юлы булап, 1,0 км әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 30 м Югары Мактама, Колшәрип авыл җирлекләре һәм «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Миңлебай авылыннан 1,8 км төньякта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Югары Мактама авыл җирлеге чиге «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Югары Мактама, Яңа Нәдер авыл җирлекләре һәм «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Тайсуган авылыннан 2,5 км төньяк-көнбатышта Дала Зәе елгасында урнашкан 71 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 10 м Дала Зәе елгасы буйлап аның уң ярына кадәр, 200 м «Әлмәт

Кузайкино авыл җирлеге чиге Аппак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кузайкино, Аппак һәм Ерсубайкино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Ялан авылыннан 2,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Ялан участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 850 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, инешне ике тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 450 м 82 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м көньякка таба һәм 30 м төньяк-көнчыгышка таба уза, инешне кисеп үтеп, 50 м 82 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 500 м авыл хуҗалыгында файдаланылмый торган җирләр буйлап Аппак, Кузайкино һәм Бота авыл җирлекләре чикләре

тоташкан урында Бота авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кузайкино авыл җирлеге чиге Ерсубайкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кузайкино, Ерсубайкино һәм Сәрән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Ялан авылыннан 2,5 км көньяк-көнбатышта Сосновка елгасында урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлын кисеп үтеп, Сосновка елгасы агымы буенча аска таба ул Кичү елгасына койган җиргә кадәр уза, Кичү елгасы агымы буенча 100 м өскә таба уза, шуннан соң, яр буендагы агач-куак полосасын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м зиратның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м һәм көнчыгышка таба 350 м инешкә кадәр бара, 2,1 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Ялан участок урманчылыгындагы 76, 77, 78, 80 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 3,0 км көньяк-көнчыгышка таба 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кузайкино авыл җирлеге чиге Сәрән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба, сынык сызык ясап, 1,7 км «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чишмә участок урманчылыгындагы 3 нче, 1 нче урман кварталларының көнчыгыш, төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м һәм көньяк-көнбатышка таба 150 м бара, аннары көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,7 км 1 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары, кибеп баручы инешне һәм Суркинская елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Кузайкино – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кузайкино, Сәрән һәм Борискино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Березовка поселогыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кузайкино авыл җирлеге чиге Борискино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып 600 м көньякка таба «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Ялан участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының көнбатыш чиге буй-

лапуза, шуннан соң 1,2 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары, Кичү елгасын кисеп үтеп, 500 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 350 м өскә таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 250 м плотинаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 30 м буаның уң яры буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 750 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м Кузайкино – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап Борискино, Кузайкино һәм Сәрән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Березовка поселогыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлмәт муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
23 нче кушымта

## Әлмәт муниципаль районының «Колшәрип авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Колшәрип авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Колшәрип авыл җирлеге «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге, Югары Мактама, Кәләй, Кичүчат, Урман-Кәләй һәм Миңлебай авыл җирлекләре белән чиктәш.

Колшәрип авыл җирлеге чиге Кәләй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Колшәрип, Кәләй авыл җирлекләре һәм «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Колшәрип авылыннан 900 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып, Малый инешен, Мурат елгасын һәм исемсез инешне кисеп үтеп, 5,4 км көньяк-көнбатышка таба Казан – Оренбург автомобиль юлы буйлап уза, аннары «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 134 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мурат елгасына кадәр бара, шуннан соң әлеге елга агымы буенча 100 м өскә таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 350 м 8 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көнбатышка таба 1,2 км 8 нче, 7 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка таба 350 м 7 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньякка таба 200 м 7 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Кәләй, Колшәрип һәм Кичүчат авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Колшәрип тимер юл станциясе поселогыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Колшәрип авыл җирлеге чиге «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Колшәрип авыл җирлеге, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Югары Мактама авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Миңлебай станциясеннән 1,8 км төньякта урнашкан 38 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 164 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 850 м төньякка таба һәм 250 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м һәм көньякка таба 1,0 км бара, шуннан соң

көньяк-көнбатышка таба 350 м күмәк бакчалар буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап, Куйбышев тимер юлы тармагын кисеп үтеп, 150 м урман массивы буйлап, 50 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сәнәгать объекты буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 162 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 162 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чигенә кадәр кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 700 м 38 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 550 м автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буйлап бара, шуннан соң 162 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк, көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 350 м, төньякка таба 300 м, көнбатышка таба 900 м уза, аннары Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап 150 м төньякка таба, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 161 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньякка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 162 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м, көнбатышка таба 50 м һәм көньяк-көнбатышка таба 50 м уза, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 158 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м төньяк-көнчыгышка таба уза, әлеге аерымланган кишәрлек буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба бара, 158 нче урман кварталының әлеге аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап 2,8 км төньяк-көнчыгышка таба 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Колшәрип авыл җирлеге чиге Югары Мактама авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Колшәрип, Югары Мактама һәм

Миңлебай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Миңлебай авылыннан 1,7 км төньякта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба1,5 км Әлмәт – Чупай автомобиль юлы булап, 1,0 км әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 30 м 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Колшәрип авыл җирлеге чиге Миңлебай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 250 м Әлмәт – Чупай автомобиль юлы буйлап уза, 150 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 185 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, Әлмәт – Чупай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап аның төньяк-көнбатыш чигенә кадәр, 200 м автоомбиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сәнәгать объекты буйлап, 100 м әлеге сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 35 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 100 м көнбатышка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 250 м профильле автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 40 м урман массивының төньяк чиге буйлап уза, аннары төньякка таба 1,1 км 44 нче, 34 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 34 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньякка таба, төньяк чиге буйлап 200 м көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 34 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 34 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 200 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м

33 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 650 м 33 нче урман кварталы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 150 м 32 нче урман кварталы буйлап бара, 200 м әлеге урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап Колшәрип, Миңлебай һәм Кичүчат авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Колшәрип тимер юл станциясе поселогыннан 2,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Колшәрип авыл җирлеге чиге Кичүчат авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 500 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 7 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м 9 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м 9 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 9 нчы, 10 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 10 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 200 м уза, 100 м 10 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 10 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м 12 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 12 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м 13 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кичүчат, Колшәрип һәм Миңлебай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Колшәрип тимер юл станциясе поселогыннан 2,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Колшәрип авыл җирлеге чиге Урман-Кәләй авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә Колшәрип авыл җирлеге һәм Урман-Кәләй авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Колшәрип авылыннан

3,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 79 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, урман массивын һәм Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 50 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 10 нчы урман кварталы буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 200 м 10 нчы, 12 нче урман кварталлары буйлап бара, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 12 нче урман кварталы буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 50 м уза, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 12 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм, урман массивын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 800 м бара, 50 м 10 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 79 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлмәт муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
24 нче кушымта

**Әлмәт муниципаль районының
«Урман-Кәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Урман-Кәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Урман-Кәләй авыл җирлеге Югары Акташ, Кәләй һәм Колшәрип авыл җирлекләре белән чиктәш.

Урман-Кәләй авыл җирлеге чиге Югары Акташ авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урман-Кәләй, Югары Акташ һәм Кәләй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кәләй тимер юл станциясе поселогыннан 1,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 100 м

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м сәнәгать объектының көньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнчыгышка таба 700 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап уза, аннары төньякка таба 250 м профильле башка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, 250 м әлеге профильле автомобиль юлы буйлап һәм 250 м аңа бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап 200 м төньякка таба, төньяк чиге буйлап 200 м көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньякка таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 200 м сәнәгать объектының төньяк чиге буйлап Урман-Кәләй, Югары Акташ һәм Кәләй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кәләй тимер юл станциясе поселогыннан 700 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Урман-Кәләй авыл җирлеге чиге Кәләй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 46 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 350 м сәнәгать объектының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Казан – Оренбург» – Кәләй тимер юл станциясе поселогы – «Чаллы – Зәй – Әлмәт» автомобиль юлына кадәр уза, аннары көнчыгышка таба 150 м әлеге автомобиль юлы буйлап, 1,1 км әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 900 м күмәк бакчаларның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап буага кадәр бара, көньяк-көнбатышка таба 150 м буаның уң яры буйлап уза, аннары инеш агымы буенча 200 м өскә таба бара, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны, «Казан – Оренбург» – Кәләй тимер юл станциясе поселогы – «Чаллы – Зәй – Әлмәт» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км һәм төньяк-көнбатышка таба 400 м, 200 м «Кәләй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бота участок урманчылыгындагы 109 нчы урман кварталы буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 850 м, төньякка таба 2,0 км 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урман-Кәләй авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Колшәрип авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урман-Кәләй авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге һәм Колшәрип авыл

җирлеге чикләре тоташкан урында Колшәрип авылыннан 3,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 79 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, урман массивын һәм Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 50 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 10 нчы урман кварталы буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 200 м 10 нчы, 12 нче урман кварталлары буйлап бара, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 12 нче урман кварталы буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 50 м уза, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 12 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм, урман массивын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 800 м бара, 50 м 10 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 79 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлмәт муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
25 нче кушымта

## Әлмәт муниципаль районының «Мәмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Мәмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Мәмәт авыл җирлеге чиге Кичүчат, Миңлебай, Иске Суркино авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш.

Мәмәт авыл җирлеге чиге Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш җирдә Мәмәт, Иске Суркино авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Суркино авылыннан 2,2 км көнбатышта урнашкан 66 нчы

тоташу ноктасыннан алып Әлмәт муниципаль районы чиге буйлап Мәмәт, Кичүчат авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сәмәрканд поселогыннан 2,1 км төньякта урнашкан 63 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Мәмәт авыл җирлеге чиге Кичүчат авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 63 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көньяк-көнчыгышка таба, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м сәнәгать объектының көньяк чиге буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр бара, 1,6 км әлеге инеш агымы буенча аска таба уза, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, «Казан – Оренбург» – Мәмәт – Чупай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнбатышка таба 450 м уза, аннары буа буйлап көньяк-көнчыгышка таба 350 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 250 м бара, шуннан соң көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м чокыр төбе буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мәмәт, Кичүчат һәм Миңлебай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мәмәт авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 64 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Мәмәт авыл җирлеге чиге Миңлебай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Мәмәт, Миңлебай һәм Иске Суркино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Суркино авылыннан 2,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 65 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 79 нчы, 78 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 78 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 150 м төньяк-көнчыгышка таба 78 нче урман кварталының

көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 200 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 78 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м 78 нче, 77 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 400 м 77 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 250 м 77 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 200 м 77 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка таба 250 м 48 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 250 м, төньяк-көнбатышка таба 200 м карьерның көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 750 м карьер буйлап уза, аннары Әлмәт – Чупай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 400 м 48 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 350 м һәм төньякка таба 300 м бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м һәм төньяк-көнбатышка таба 200 м 47 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 950 м көнбатышка таба 47 нче, 31 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң 100 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 350 м һәм кабат төньяк-көнбатышка таба 150 м 31 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,5 км 31 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 64 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Мәмәт авыл җирлеге чиге Иске Суркино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 65 нче тоташу ноктасыннан алып, профильле автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, көньякка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 500 м «Әлмәт урманчылыгы» Татар-

стан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 92 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 92 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Иске Суркино авылын Әлмәт – Чупай автомобиль юлы белән тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 66 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлмәт муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>26 нчы кушымта

**Әлмәт муниципаль районының «Миңлебай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Миңлебай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Миңлебай авыл җирлеге Васильевка, Югары Мактама, Кичүчат, Колшәрип, Мәмәт һәм Иске Суркино авыл җирлекләре белән чиктәш.

Миңлебай авыл җирлеге чиге Колшәрип авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Миңлебай, Колшәрип һәм Югары Мактама авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Миңлебай авылыннан 1,7 км төньякта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 250 м Әлмәт – Чупай автомобиль юлы буйлап уза, 150 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 185 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап, Әлмәт – Чупай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап аның төньяк-көнбатыш чигенә кадәр, 200 м автоомбиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сәнәгать объекты буйлап, 100 м әлеге сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 35 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 100 м көнбатышка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 100 м сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 250 м профильле автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 40 м урман массивының төньяк чиге буйлап уза, аннары төньякка таба 1,1 км 44 нче, 34 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 34 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньякка таба, төньяк чиге буйлап 200 м көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба уза, аннары 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 34 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 34 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 200 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м 33 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 650 м 33 нче урман кварталы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 150 м 32 нче урман кварталы буйлап бара, 200 м әлеге урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап Миңлебай, Колшәрип һәм Кичүчат авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Колшәрип тимер юл станциясе поселогыннан 2,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Миңлебай авыл җирлеге чиге Югары Мактама авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Миңлебай, Югары Мактама һәм Васильевка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Васильевка авылыннан 2,0 км төньякта урнашкан 69 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 3,6 км Әлмәт – Лениногорск автомобиль юлы буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м урман массивының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м һәм төньяк-көнбатышка таба 250 м уза, 150 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Респуб-

ликасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 174 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көнбатышка таба 300 м урман массивының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 174 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 650 м һәм төньяк-көнбатышка таба 300 м уза, шуннан соң 100 м 174 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр бара, аннары бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба һәм әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 350 м тимер юл буйлап һәм 150 м әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м һәм төньяк-көнбатышка таба 50 м 58 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, урман массивын кисеп үтеп, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, төньяк-көнчыгышка таба 150 м һәм төньяк-көнбатышка таба 50 м уза, 100 м 46 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 200 м 46 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 100 м 45 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 100 м 45 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 450 м 45 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Әлмәт – Чупай» – Миңлебай станциясе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м урман массивының төньяк чиге буйлап Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр уза, тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң, әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м көнбатышка

таба, 100 м тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Миңлебай авыл җирлеге чиге Васильевка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Миңлебай, Васильевка һәм Иске Суркино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Васильевка авылыннан 2,8 км көнбатышта урнашкан 67 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 50 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 84 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м 82 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 150 м 82 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 900 м 82 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 150 м 82 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 650 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км һәм көньяк-көнчыгышка таба 50 м Әлмәт – Лениногорск автомобиль юлына кадәр, 69 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Миңлебай авыл җирлеге чиге Иске Суркино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 67 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 150 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 84 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары, профильле автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 84 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 84 нче, 83 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 150 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 300 м 83 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 100 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 450 м 83 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сәнәгать объекты буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 400 м 83 нче, 79 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 79 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Миңлебай, Иске Суркино һәм Мәмәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Суркино авылын-

нан 2,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 65 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Миңлебай авыл җирлеге Мәмәт чиге авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 65 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 79 нчы, 78 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 78 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 150 м төньяк-көнчыгышка таба 78 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 200 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 78 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м 78 нче, 77 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 400 м 77 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 250 м 77 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 200 м 77 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка таба 250 м 48 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 250 м, төньяк-көнбатышка таба 200 м карьерның көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 750 м карьер буйлап уза, аннары Әлмәт – Чупай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 400 м 48 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 350 м һәм төньякка таба 300 м бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м һәм төньяк-көнбатышка таба 200 м 47 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 950 м көнбатышка таба 47 нче, 31 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң 100 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка

таба 350 м һәм кабат төньяк-көнбатышка таба 150 м 31 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,5 км 31 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Миңлебай, Мәмәт һәм Кичүчат авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мәмәт авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 64 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Миңлебай авыл җирлеге чиге Кичүчат авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 64 нче тоташу ноктасыннан алып «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Миңлебай участок урманчылыгындагы 31 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 500 м, 250 м 31 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 100 м, сынык сызык ясап, 3,2 км 31, 47, 48 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Әлмәт – Чупай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,0 км 48 нче, 77 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш, төньяк чикләре буйлап бара, аннары, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кичү елгасына кадәр уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән һәм Әлмәт – Чупай автоомбиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, әлеге елга агымы буенча 650 м аска таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Кичү елгасын кисеп үтеп, 300 м 49 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 950 м 49 нчы, 43 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап бара, 150 м сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 450 м 43 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 43 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м 43 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап һәм 42 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 150 м 196 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 42 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 200 м төньякка таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка

таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньякка таба 600 м 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м 42 нче, 32 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км 32 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 40 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Әлмәт муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
27 нче кушымта

**Әлмәт муниципаль районының
«Түбән Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Абдул авыл җирлеге Баграж-Никольский, Елхово авыл җирлекләре һәм Чирмешән муниципаль районы белән чиктәш.

Түбән Абдул авыл җирлеге чиге Чирмешән муниципаль районы белән чиктәш җирдә Түбән Абдул, Баграж-Никольский авыл җирлекләре һәм Чирмешән муниципаль районы чикләре тоташкан урында Аргы Ивановка авылыннан 3,0 км көньякта Чишмә елгасында урнашкан 57 нче тоташу ноктасыннан алып Әлмәт муниципаль районы чиге буйлап Түбән Абдул, Елхово авыл җирлекләре һәм Чирмешән муниципаль районы чикләре тоташкан урында Түбән Абдул авылыннан 3,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Абдул авыл җирлеге чиге Баграж-Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Абдул, Баграж-Никольский һәм Елхово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Көч авылыннан 200 м көнчыгышта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасыннан алып Чишмә елгасы агымы буенча 3,7 км аска

таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 15 м әлеге елга буйлап аның уң ярына кадәр, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,2 км көнбатышка таба һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, көньякка таба 50 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап уза, көньяк-көнчыгышка таба 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Чишмә елгасына кадәр бара, 10 м әлеге елга буйлап һәм 350 м аның агымы буенча аска таба 57 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Абдул авыл җирлеге чиге Елхово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 58 нче тоташу ноктасыннан алып 2,2 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Чишмә елгасына кадәр уза, әлеге елга буенча 15 м һәм, Кузайкино – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аның агымы буенча аска таба 4,0 км бара, аннары 3,5 км Чишмә елгасының кибеп баручы ермагы агымы буенча аска таба елга тамагына кадәр уза, шуннан соң 2,4 км әлеге елга агымы буенча аска таба 56 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлмәт муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
28 нче кушымта

## Әлмәт муниципаль районының «Яңа Кәшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Яңа Кәшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яңа Кәшер авыл җирлеге Кама-Исмәгыйль, Яңа Нәдер, Яңа Никольский, Иске Михайловка һәм Сөләй авыл җирлекләре белән чиктәш.

Яңа Кәшер авыл җирлеге чиге Иске Михайловка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кәшер, Иске Михайловка һәм Сөләй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Болгар-1

авылыннан 2,1 км көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 1,9 км «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Поташ Аланы участок урманчылыгындагы 72, 71, 70 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 70 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 400 м 70 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 250 м 70 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, 700 м 69 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, инешне кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Әлмәт – Мөслим автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 450 м бара, шуннан соң төньякка таба 950 м 69 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көнбатышка таба 1,1 км 65 нче, 64 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 700 м 64 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап һәм төньякка таба 900 м көнбатыш чиге буйлап, Рус Акташы – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка таба 2,0 км 54, 53, 52 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 200 м һәм төньяк-көнбатышка таба 150 м 62 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кәске Чишмәсе инешенә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 350 м аска таба Яңа Кәшер, Иске Михайловка һәм Яңа Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бикәсаз авылыннан 750 м төньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Кәшер авыл җирлеге чиге Сөләй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Кәшер, Сөләй һәм Кама-Исмәгыйль авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Кәшер авылыннан 3,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, Танаевка – Яңа Кәшер автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,0 км, көнбатышка таба 450 м бара, 50 м сәнәгать объектының төньяк чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, аның агымы буенча 900 м аска таба бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м буа буйлап уза, Әлмәт – Азнакай автомобиль юлына бүлеп бирелгән һәм профильле автомобиль юлы-

Тайсуган авыл җирлеге чиге Бишмунча авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Тайсуган, Бишмунча авыл җирлекләре һәм Бөгелмә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кама-Елга авылыннан 3,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньякка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кама-Исмәгыйль

участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 89 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнбатышка таба 550 м 89 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 89 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 200 м һәм көньяк-көнбатышка таба 450 м 88 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 550 м 88 нче, 94 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м, урман массивын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 300 м уза, 87 нче урман кварталы буйлап 400 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 600 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 200 м 87 нче урман кварталы буйлап, Кодаш — Кама-Исмагыйль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 450 м 87 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 87 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 74 нче урман кварталына кадәр бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 550 м әлеге урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м 74 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 600 м 74 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба, 300 м көньякка таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м 74 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 150 м 74 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 74 нче, 70 нче урман кварталларының көньяк, көнбатыш һәм

төньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,1 км төньякка таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 250 м 70 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 100 м 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 300 м уза, төньяк-көнбатышка таба 200 м 72 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м 72 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 250 м һәм төньякка таба 250 м, урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, сәнәгать объектының көнбатыш чиге буйлап 50 м, төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м бара, шуннан соң 700 м 72 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бишмунча, Тайсуган һәм Яңа Нәдер авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тайсуган авылыннан 2,5 км төньякта урнашкан 80 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Тайсуган авыл җирлеге чиге Бөгелмә муниципаль районы белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып Әлмәт муниципаль районы чиге буйлап 76 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлмәт муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
38 нче кушымта

**Әлмәт муниципаль районының «Ямаши авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Ямаши авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ямаши авыл җирлеге Борискино, Яңа Троицкий авыл җирлекләре, Зәй, Түбән Кама һәм Яңа Чишмә муниципаль районнары белән чиктәш.

Ямаши авыл җирлеге чиге Яңа Чишмә муниципаль районы белән чиктәш җирдә Ямаши, Яңа Троицкий авыл җирлекләре һәм Яңа Чишмә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Шөгерчә авылыннан 2,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче тоташу ноктасыннан алып Әлмәт муниципаль районы чиге буйлап Ямаши авыл җирлеге, Яңа Чишмә һәм Түбән Кама муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Рокашево авылыннан 2,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 2 нче (83 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямаши авыл җирлеге чиге Түбән Кама муниципаль районы белән чиктәш җирдә 2 нче (83 нче) тоташу ноктасыннан алып Әлмәт муниципаль районы чиге буйлап Ямаши авыл җирлеге, Зәй һәм Түбән Кама муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Ямаши авылыннан 11,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче (84 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямаши авыл җирлеге чиге Зәй муниципаль районы белән чиктәш җирдә 3 нче (84 нче) тоташу ноктасыннан алып Әлмәт муниципаль районы чиге буйлап Ямаши, Борискино авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Красная Горка авылыннан 2,5 км көнчыгышта урнашкан 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямаши авыл җирлеге чиге Борискино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямаши, Борискино һәм Яңа Троицкий авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Шөгерчә авылыннан 3,3 км көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буйлап, 300 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге инеш агымы буенча 2,8 км аска таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м буа буйлап, инеш агымы буенча 450 м аска таба Кичү елгасына кушылган җиргә кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 3,0 км өскә таба уза, аннары, яр буендагы урман полосасын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Зәй урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ямаши участок урманчылыгындагы 104 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш

чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 400 м 104 нче, 105 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 200 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м 105 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, көнчыгышка таба 250 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 900 м уза, 150 м 105 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м 105 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 650 м 105 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 750 м 105 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 700 м 103 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямаши авыл җирлеге чиге Яңа Троицкий авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 1 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 1,1 км аска таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 4,9 км көньяк-көнчыгышка таба, 1,1 км көньякка таба һәм 400 м көньяк-көнчыгышка таба Яңа Троицкий – Ямаши автомобиль юлына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 600 м әлеге автомобиль юлы буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әлмәт муниципаль районы»<br>муниципаль берәмлегенең һәм аның<br>составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>39 нчы кушымта

**Әлмәт муниципаль районының «Ямаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Ямаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның соста-

вындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ямаш авыл җирлеге Югары Акташ, Кәләй, Яңа Никольский, Рус Акташы авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы белән чиктәш.

Ямаш авыл җирлеге чиге Зәй муниципаль районы белән чиктәш җирдә Ямаш, Рус Акташы һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Рус Акташы авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта Мостай елгасында урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып Әлмәт муниципаль районы чиге буйлап Ямаш, Яңа Никольский авыл җирлекләре һәм Зәй муниципаль районы чикләре тоташкан урында Березовка авылыннан 1,6 км төньякта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямаш авыл җирлеге чиге Яңа Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 2,6 км һәм төньяк-көнчыгышка таба 550 м «Зәй – Бохарай» – Урсай – Әлмәт автомобиль юлына кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,7 км әлеге автомобиль юлы буйлап Рус Акташы – Азнакай автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап 450 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Поташ Аланы участок урманчылыгындагы 73 нче урман кварталы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 73 нче урман кварталы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м 73 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, «Зәй – Бохарай» – Урсай – Әлмәт автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м әлеге урман кварталы буйлап, 50 м сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м 73 нче урман кварталы буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 73 нче урман кварталы буйлап уза, 150 м әлеге урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 450 м 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 100 м сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 600 м 74 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м 96 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, Ямаш елгасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,0 км 96 нчы, 95 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м 95 нче,

113 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 113 нче, 127 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м 111 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 50 м сәнәгать объекты буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 200 м төньякка таба бара, 50 м 111 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 50 м 111 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 111 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 111 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, сәнәгать объектын кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м 111 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 50 м 110 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 110 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньякка таба 450 м 110 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 109 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 300 м 109 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сәнәгать объекты буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 300 м 109 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 250 м 109 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 109 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 109 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м 109 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, көньякка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 800 м 109 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, 750 м

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 110 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 110 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м 112 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньякка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50 м һәм көнчыгышка таба 50 м 112 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 112 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м көньякка таба һәм, сынык сызык ясап, көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары көнчыгышка таба 200 м 112 нче, 111 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң, инешне кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 750 м 127 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 300 м 127 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,2 км күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сәнәгать объектының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 400 м 141 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 800 м 141 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ямаш, Яңа Никольский һәм Кәләй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Нолинка авылыннан 2,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ямаш авыл җирлеге чиге Кәләй авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямаш, Кәләй һәм Югары Акташ авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Нолинка авылыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 200 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м авыл хуҗалыгында файдаланылмый торган җирләрнең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямаш авыл җирлеге чиге Югары Акташ авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямаш, Югары Акташ һәм Рус Акташы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Акташ станциясеннән

2,3 км төньяк-көнчыгышта Одногулка елгасында урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып Одногулка елгасы агымы буенча 350 м аска таба уза, аннары төньякка таба 50 м буа буйлап бара, Одногулка елгасы агымы буенча 850 м аска таба Дала Зәе елгасына кушылган җиргә кадәр бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге елга агымы буенча 6,5 км өскә таба уза, аннары Дала Зәе елгасы буенча 10 м төньяк-көнчыгышка таба уң ярына кадәр, сынык сызык ясап, 300 м «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Поташ Аланы участок урманчылыгындагы 171 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 200 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 250 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 171 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, күлне кисеп үтеп, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Югары Акташ, Ямаш һәм Кәләй авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Нолинка авылыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Ямаш авыл җирлеге чиге Рус Акташы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 2,8 км көньяк-көнчыгышка таба Чаллы – Зәй – Әлмәт автомобиль юлы буйлап уза, аннары Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м төньяк-көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,2 км төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 850 м «Чаллы – Зәй – Әлмәт» – Зәй-Чишмә – Ямаши автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Дала Зәе елгасына кадәр уза, 10 м әлеге елга буйлап һәм аның агымы буенча өскә таба 9,7 км Рус Акташы – Азнакай автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 1,6 км әлеге автомобиль юлы буйлап уза, аннары, урман полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Одногулка елгасына кадәр, 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1385. Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Буа муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен үзгәртергә:

1) «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге» һәм «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

2) «Адав-Толымбай авыл җирлеге» һәм «Карлы авыл җирлеге» әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә;

3) «Тимбай авыл җирлеге» һәм «Янтуган авыл җирлеге» әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 1, № 12 (V өлеш); 2010, № 7 (I өлеш) әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 30 декабре
№ 150-ТРЗ

"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Буа муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

Муниципаль берәмлекләр чикләренең үзгәрешләр исәпкә алынган

## карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Буа муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - "Буа шәһәре" муниципаль берәмлегенең һәм Татар Буасы авыл җирлегенең чиктәш чиге

В-Г - "Буа шәһәре" муниципаль берәмлегенең һәм Түбән Наратбаш авыл җирлегенең чиктәш чиге

- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар

- Буа муниципаль районының "Буа шәһәре" муниципаль берәмлегенең Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге территориясе составына кертелүче территориясе

- Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлегенең Буа муниципаль районының "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче территориясе

- Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Буа муниципаль районының "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче территориясе

Муниципаль берәмлекләр чикләренең үзгәрешләр исәпкә алынган

## карта-схемасы

"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Буа муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта




Шартлы билгеләр

- Буа муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - Адав-Толымбай авыл җирлегенең һәм Карлы авыл җирлегенең чиктәш чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлегенең Буа муниципаль районының Карлы авыл җирлеге территориясе составына кертелүче территориясе

Муниципаль берәмлекләр чикләренең үзгәрешләр исәпкә алынган

## карта-схемасы

"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Буа муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге

- Буа муниципаль районы чиге

- муниципаль берәмлекләр чикләре

- А-Б - Тимбай авыл җирлегенең һәм Янтуган авыл җирлегенең чиктәш чиге

- җирлекләрнең административ үзәкләре

- торак пунктлар

- Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлегенең Буа муниципаль районының Тимбай авыл җирлеге территориясе составына кертелүче территориясе

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен үзгәртү
һәм «Буа муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

**«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелә торган үзгәрешләр**

1 – 33 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Буа муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Буа муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *70(5) - 67(6)* | - Чүпрәле муниципаль районы |
| *67(6) - 6(7)* | - Чуаш Республикасы |
| *6(7) - 33(36)* | - Апас муниципаль районы |
| *33(36) - 75(4)* | - Тәтеш муниципаль районы |
| *75(4) - 79(4в)* | - Ульяновск өлкәсе |
| *79(4в) - 78(4г)* | - Чүпрәле муниципаль районы |
| *78(4г) - 70(5)* | - Ульяновск өлкәсе |
| *71(5а) - 82(5б)* | - Ульяновск өлкәсе |
| *82(5б) - 71(5а)* | - Чүпрәле муниципаль районы |
| *6а (2 участок)* | - Чуаш Республикасы |

# «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Буа шәһәре |
| 2 | Адав-Толымбай авыл җирлеге |
| 3 | Аксу авыл җирлеге |
| 4 | Әлши авыл җирлеге |
| 5 | Алших авыл җирлеге |
| 6 | Бик-Үти авыл җирлеге |
| 7 | Зур Фролово авыл җирлеге |
| 8 | Боерган авыл җирлеге |
| 9 | Югары Лашчы авыл җирлеге |
| 10 | Исәк авыл җирлеге |
| 11 | Кайбыч авыл җирлеге |
| 12 | Кыят авыл җирлеге |
| 13 | Күшке авыл җирлеге |
| 14 | Шәмәк авыл җирлеге |
| 15 | Татар Буасы авыл җирлеге |
| 16 | Карлы авыл җирлеге |
| 17 | Мөкерле авыл җирлеге |
| 18 | Түбән Наратбаш авыл җирлеге |
| 19 | Яңа Тинчәле авыл җирлеге |
| 20 | Яңа Чәчкап авыл җирлеге |
| 21 | Норлат авыл җирлеге |
| 22 | Ырынгы авыл җирлеге |
| 23 | Кырык Садак авыл җирлеге |
| 24 | Иске Суыксу авыл җирлеге |
| 25 | Иске Тинчәле авыл җирлеге |
| 26 | Тимбай авыл җирлеге |
| 27 | Күл Черкене авыл җирлеге |
| 28 | Килдураз авыл җирлеге |
| 29 | Чуаш Киштәге авыл җирлеге |
| 30 | Янтуган авыл җирлеге |
| 31 | Яшевка авыл җирлеге |

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**«Буа муниципаль районы»**
**муниципаль берәмлеге территориясе чигенең**
**картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Буа муниципаль районы Чүпрәле, Апас, Тәтеш муниципаль районнары, Чуваш Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Буа, Тәтеш муниципаль районнары һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Раково авылыннан 450 м көньякта Чынлы елгасы акваториясендә урнашкан 75 нче (4 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Буа, Чүпрәле муниципаль районнары һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Таковар авылыннан 2,7 км төньякта урнашкан 70 нче (5 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Чүпрәле муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 70 нче (5 нче) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба, «Казан – Ульяновск» – Иске Чүпрәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көнбатышка таба 900 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м, көнбатышка таба һәм төньякка таба 3,5 км, текә ярлы кишәрлекне кисеп үтеп, Олы Тилчә елгасына кадәр уза, шушы елга агымы буенча өскә таба 6,3 км, көньяк-көнбатышка таба, Олы Тилчә елгасының текә ярын, «Казан – Ульяновск» – Иске Чүпрәле» – Яңа Тинчәле автомобиль юлына бүлеп бирелгән

полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,4 км бара, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,2 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, төньяк-көнбатышка таба 2,6 км, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,1 км, яңадан әлеге кибеп баручы инешне кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 3,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м Буа, Чүпрәле муниципаль районнары һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Чынлы авылыннан 3,9 км көнба-тышта урнашкан 67 нче (6 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Чуваш Республикасы белән чиктәш җирдә 67 нче (6 нчы) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Буа, Апас муниципаль районнары һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Аксу авылыннан 4,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 6 нчы (7 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең чиге «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 6 нчы (7 нче) тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары агач-куак үсемлекләре массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м көньяк-көнчыгышка таба, Чирмешән – Яльчик автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнчыгышка таба 350 м, көньякка таба 50 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча аска таба 1,7 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 150 м, көньяк-көнбатышка таба 250 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,3 км инешкә кадәр уза, шуннан соң инеш агымы буенча аска таба 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 250 м, көньяк-көнчыгышка таба 750 м, көньяк-көнбатышка таба 300 м инешкә кадәр, шушы инеш агымы буенча аска таба 2,5 км аның Бола елгасына койган җиренә кадәр бара, әлеге елга агымы буенча аска таба 6,5 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км, көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км уза, шуннан соң, урман полосасын һәм Буа – Каратун автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км, көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык

ясап, 1,1 км бара, аннары көньякка таба 500 м урман полосасы буйлап, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 600 м, чокырларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 350 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 300 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шушы инеш агымы буенча аска таба 750 м, көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасы буйлап 50 м, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, агач-куак үсемлекләре массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, көнчыгышка таба киптерелгән канау буйлап 350 м Зөя елгасына кадәр уза, 20 м шушы елга агымы буйлап һәм аның агымы буенча аска таба 1,2 км бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 30 м Зөя елгасы буйлап аның уң ярына кадәр уза, шуннан соң 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасы буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м, сынык сызык ясап, «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 450 м, төньяк-көнбатышка таба 50 м урман массивы буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,0 км, төньяк-көнчыгышка таба 700 м, агач-куак үсемлекләре массивы буйлап 200 м Зөя елгасына кадәр бара, аннары 30 м шушы елга буйлап һәм 7,9 км аның агымы буенча аска таба, төньяк-көнчыгышка таба 20 м шушы елга буйлап аның уң ярына кадәр уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, көньяк-көнчыгышка таба 250 м урман массивы буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 250 м, көньяк-көнчыгышка таба 600 м бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 650 м 17, 19, 21 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм көньякка таба 2,3 км көнбатыш чиге буйлап, чокырларны һәм инешләрне кисеп үтеп, көнчыгышка таба 750 м 21 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң көньякка таба 1,5 км урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м агач-куак үсемлекләре массивының көнбатыш чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба, инешне кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 50 м урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап, көньякка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, Бәбки — Төбәк-Черкене автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м

урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 3,9 км 43, 48, 49, 56 нчы урман кварталларының һәм 65 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Буа, Апас һәм Тәтеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Дүртөйле авылыннан 5,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче (36 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 75 нче (4 нче) тоташу ноктасыннан алып Чынлы елгасы агымы буенча аска таба 1,2 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,4 км, агач-куак үсемлекләренең яр буе массивын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,5 км, көньяк-көнбатышка таба 250 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,7 км, көньяк-көнчыгышка таба 200 м Зөя елгасына кадәр, шушы елга агымы буенча аска таба, «Казан – Ульяновск» – Олы Тархан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 24,1 км Килнә елгасы тамагына кадәр уза, аннары 2,0 км шушы елга агымы буенча өскә таба инеш тамагына кадәр бара, шуннан соң шушы инеш агымы буенча өскә таба 300 м, буа буйлап 150 м, инеш агымы буенча өскә таба 2,9 км уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 2,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң шушы инеш агымы буенча өскә таба 650 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 2,9 км, буаны кисеп үтеп, «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 81, 82, 83, 87 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне һәм буаларны кисеп үтеп, 7,4 км 87, 88, 85, 86, 80 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш, көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап инешкә кадәр бара, шуннан соң инеш агымы буенча аска таба 2,0 км буага кадәр уза, аннары 20 м буаның уң яры буйлап һәм 20 м төньякка таба, буаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 127 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м 127 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км һәм төньяк-көнчыгышка таба 950 м уза, аннары, сынык сызык ясап, төньякка таба, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 7,7 км «Тәтеш урманчылыгы» Та-

тарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 57, 56, 55, 54, 52, 51 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 200 м, төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 950 м 48 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 400 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, көньяк-көнбатышка таба 200 м һәм төньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 6,9 км 40, 39, 38, 32 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш, көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, инешләрне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 700 м 32 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км 32 нче урман кварталының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап һәм 28 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 2,8 км 22 нче, 21 нче урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, урман полосасының көньяк чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешләрне һәм Шигали һәм Тоншерма авылларын тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 2,7 км уза, аннары урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км бара, шуннан соң көнбатышка таба 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 550 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 400 м төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м урман утыртмалары буйлап, 2,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны кисеп үтеп, 50 м 126 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 3,5 км 64, 62, 59 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш, көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 450 м 59 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары, Кыят – Күгәлнә – Тоншерма автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, шуннан соң

төньяк-көнбатышка таба 50 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм төньякка таба 250 м уза, аннары урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 4,2 км 50 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап Зөя елгасына кадәр уза, чокырны кисеп үтеп, шушы елга агымы буенча аска таба 2,8 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 500 м, күлне кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба, аның сул ярының текә кишәрлеген кисеп үтеп, 350 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча өскә таба 600 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 400 м чокыр төбеннән, чокырның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км уза, 350 м чокырның көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Буа — Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, чокыр төбеннән 400 м Тоша елгасына кадәр бара, аннары шушы елга агымы буенча аска таба 200 м аңа коя торган инеш тамагына кадәр уза, шуннан соң шушы инеш агымы буенча өскә таба 1,4 км әлеге инешкә коя торган кибеп баручы инеш тамагына кадәр бара, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 350 м, төньяк-көнчыгышка таба 100 м урман массивы буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 800 м 36 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м уза, аннары төньякка таба 100 м урман полосасы буйлап, 50 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 350 м бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 152 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм, сынык сызык ясап, 2,1 км шушы участок урманчылыгындагы 8 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап,

1,2 км урман полосасы буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,0 км урман полосасы буйлап, 50 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 40 м түбәнлектәге сазлыкның көнчыгыш чиге буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 113 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 100 м урман массивының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м һәм төньяк-көнбатышка таба 700 м, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң урман полосасы буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 30 м 113 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м бара, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Ульяновск федераль юлын һәм «Апас – Тәтеш» – Олы Шәмәк – Кече Шәмәк автомобиль юлын тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм текә кишәрлекне кисеп үтеп, 750 м уза, аннары төньякка таба 20 м 113 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап һәм көнбатышка таба 50 м төньяк чиге буйлап бара, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 113 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң 50 м урман массивының көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буе урман полосаларын кисеп үтеп, 50 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 1,7 км «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 58 нче, 57 нче урман кварталларының көнчыгыш, төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап, көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 550 м 57 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 400 м 65 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 33 нче (36 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Чүпрәле муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге, «Чүпрәле муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлеге һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Новоселки авылыннан 700 м көньяк-көнчыгышта Иске Чынлы елгасы ермагында урнашкан 78 нче (4г) тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 250 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 400 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосадагы урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, төньякка таба, Чынлы елгасын кисеп үтеп, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба сәнәгать объектының көньяк, көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, 200 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,5 км Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосадагы урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 2,6 км Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 350 м, төньяк-көнчыгышка таба 450 м уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 200 м «Казан – Ульяновск» – Борындык тимер юл станциясе поселогы автомобиль юлы буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,2 км, көньяк-көнчыгышка таба 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, сынык сызык ясап, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м сәнәгать объектының көнчыгыш чиге буйлап, сәнәгать объекты буйлап 200 м көньякка таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 500 м сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 250 м Боерган – Борындык тимер юл станциясе поселогы автомобиль юлы буйлап, төньяк-көнбатышка таба 700 м Әлши – Борындык тимер юл станциясе поселогы автомобиль юлы буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м, төньяк-көнбатышка таба 200 м, көньяк-көнбатышка таба 250 м сәнәгать объектының көнчыгыш чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 100 м зиратның төньяк чиге буйлап, көньяк-көнбатышка таба 150 м көнчыгыш чиге буйлап һәм төньяк-көнбатышка таба 50 м көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 3,2 км Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы

инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 900 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосадагы урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,2 км Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап, Чынлы елгасын кисеп үтеп, Буа муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районының басу аша кишәрлеге һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Новоселки авылыннан 850 м көньяк-көнчыгышта Иске Чынлы елгасы ермагында урнашкан 79 нчы (4в) тоташу ноктасына кадәр уза.

Карлы авыл җирлеге чиге Түбән Наратбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 20 м, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м агач-куак үсемлекләре массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 400 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 250 м урман массивының көньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 800 м агач-куаклыклар полосасының көнчыгыш чиге буйлап канауга кадәр бара, шуннан соң канау буйлап көньяк-көнчыгышка таба 300 м һәм көнчыгышка таба 100 м Карлы елгасына кадәр уза, 550 м шушы елга агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 41 нче урман

кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Карлы, Түбән Наратбаш һәм Адав-Толымбай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Адав-Толымбай авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта ур-нашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Карлы авыл җирлеге чиге Адав-Толымбай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 1,7 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Вольнистан – Кыят – Яшевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м үләт базының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 400 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, җитештерү объекты буйлап 200 м һәм төньяк-көнбатышка таба 50 м бара, 50 м 47 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м әлеге урман кварталы буенча уза, төньякка таба, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 47 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 300 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м 47 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м уза, сынык сызык ясап, 1,0 км 47 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м 45 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм төньяк-көнчыгышка таба 150 м төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Буа – Адав-Толымбай – Ивашевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 650 м 45 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньякка таба 450 м 43 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап һәм төньяк-көнчыгышка таба 200 м төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 43 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 250 м 43 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
19 нчы кушымта

**Буа муниципаль районының «Мөкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Мөкерле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Мөкерле авыл җирлеге Алших, Югары Лашчы, Яңа Тинчәле, Ырынгы, Иске Тинчәле, Тимбай авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Мөкерле авыл җирлеге чиге Югары Лашчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Мөкерле, Югары Лашчы һәм Ырынгы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Отрада авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак үсемлекләре массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 800 м шушы инеш агымы буенча аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 40 м, инешнең текә уң ярын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,0 км, төньяк-көнбатышка таба 600 м, көньяк-көнбатышка таба 30 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, аның текә сул ярын кисеп үтеп, 350 м шушы инеш агымы буенча аска таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 40 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 117 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м 117 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап уза, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 117 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап Мөкерле,

Югары Лашчы авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Мөкерле авылыннан 2,7 км төньякта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Мөкерле авыл җирлеге чиге Ырынгы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 650 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 400 м урман полосасы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мөкерле, Ырынгы һәм Алших авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Отрада авылыннан 750 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Мөкерле авыл җирлеге чиге Алших авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып Карлы елгасы агымы буенча өскә таба 850 м бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак үсемлекләренең яр буе массивын кисеп үтеп, көньякка таба 650 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 117 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Вольнистан – Кыят – Яшевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буе урман полосасын кисеп үтеп, 2,5 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 300 м шушы инеш агымы буенча өскә таба, плотинаны кисеп үтеп, буага кадәр уза, көньяк-көнбатышка таба 150 м шушы буа буйлап, 30 м инеш агымы буенча өскә таба кушыла торган кибеп баручы инешләр тамагына кадәр бара, 2,9 км төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мөкерле, Алших һәм Иске Тинчәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сарсаз авылыннан 3,1 км төньякта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Мөкерле авыл җирлеге чиге Иске Тинчәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 56 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 2,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мөкерле, Иске Тинчәле һәм Яңа Тинчәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сарсаз авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 57 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Мөкерле авыл җирлеге чиге Яңа Тинчәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 57 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак үсемлекләре полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мөкерле, Яңа Тинчәле һәм Тимбай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Тинчәле авылыннан 6,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Мөкерле авыл җирлеге чиге Тимбай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 58 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 900 м урман полосаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 900 м төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,5 км һәм төньякка таба 950 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 2,7 км, урман полосасын, Вольнистан – Кыят – Яшевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, кибеп баручы инешне һәм Карлы елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 250 м, Карлы елгасын ике мәртәбә кисеп үтеп, Мөкерле, Тимбай авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Ямбулат авылыннан 700 м төньяк-көнбатышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Мөкерле авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасы белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 20 нче кушымта

**Буа муниципаль районының «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Наратбаш авыл җирлеге «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге, Адав-Толымбай, Зур Фролово, Кайбыч, Карлы, Күл Черкене авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш.

Түбән Наратбаш авыл җирлеге чиге Кайбыч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Наратбаш, Кайбыч һәм Күл Черкене авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Наратбаш авылыннан 1,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 40 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 300 м бара, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м урман полосасы буйлап, 650 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап уза, шуннан соң көньякка таба 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Түбән Наратбаш, Кайбыч авыл җирлекләре һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Бикмураз авылыннан 2,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Наратбаш авыл җирлеге чиге Күл Черкене авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Наратбаш, Күл Черкене һәм Зур Фролово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Күл Черкене авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта Зөя елгасында урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып Зөя елгасы агымы буенча аска таба 1,6 км бара, көньяк-көнбатышка таба 40 м аңа коючы кибеп баручы инеш тамагына кадәр бара, 950 м шушы инеш агымы буенча өскә таба аның чишмә башына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м урман полосасы буйлап, 350 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары урман полосасы буйлап көньякка таба 100 м һәм көнбатышка таба 1,4 км, Буа – Килдураз автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,0 км урман полосасының төньяк чиге буйлап, 800 м урман полосасы буйлап, 50 м аның төньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Наратбаш авыл җирлеге чиге Зур Фролово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Наратбаш, Зур Фролово авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Зур Кырлаңгы авылыннан 4,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 10 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 115 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, 350 м шушы инеш агымы буенча аска таба буага кадәр бара, көнбатышка таба 100 м шушы буа буйлап уза, 3,8 км инеш агымы буенча аска таба аның Тоша елгасына койган җиренә кадәр бара, 100 м шушы елга агымы буенча аска таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак үсемлекләренең яр буе полосасын кисеп үтеп, 350 м 114 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, 200 м 114 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, Буа – Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м 114 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап Зөя елгасының уң ярына кадәр бара, төньяк-көнбатышка таба 1,3 км елганың шушы яры буйлап уза, көньяк-көнбатышка таба 20 м Зөя елгасы буйлап һәм 7,5 км аның агымы буенча аска таба, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Наратбаш авыл җирлеге чиге Адав-Толымбай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Адав-Толымбай, Карлы һәм Түбән Наратбаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Адав-Толымбай авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 1,2 км «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 41 нче, 42 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,2 км 42 нче, 39 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 100 м сазлык буйлап, 15 м 122 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 200 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 200 м җиләк-җимеш питомнигының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 200 м бара, шуннан соң 300 м җиләк-җимеш питомнигының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 30 м Затон күле буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км һәм төньяк-көнбатышка таба 40 м шушы күл буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак үсемлекләре массивын кисеп үтеп, 100 м сазлык буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 20 м күл буйлап, 100 м сазлык буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, 100 м 122 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, җиләк-җимеш питомнигының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 350 м уза, 50 м 122 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, зират буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, көньяк-көнбатышка таба 100 м 122 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап һәм төньяк-көнбатышка таба 150 м көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 850 м 40 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм төньякка таба 100 м бара, төньяк-көнбатышка таба 300 м 40 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 450 м Зөя елгасына кадәр

бара, 20 м шушы елга буйлап һәм 3,2 км аның агымы буенча өскә таба Түбән Наратбаш, Адав-Толымбай авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Зур Кырлаңгы авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта Зөя елгасында урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Наратбаш авыл җирлеге чиге Карлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Наратбаш, Карлы авыл җирлекләре һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Адав-Толымбай авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 20 м, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м агач-куак үсемлекләре массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 400 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 250 м урман массивының көньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 800 м агач-куак үсемлекләре полосасының көнчыгыш чиге буйлап канауга кадәр бара, шуннан соң канау буйлап көньяк-көнчыгышка таба 300 м һәм көнчыгышка таба 100 м Карлы елгасына кадәр уза, 550 м шушы елга агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Наратбаш авыл җирлеге чиге «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, 250 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап профильле автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 550 м шушы автомобиль юлы буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 550 м сәнәгать объектының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм төньяк-көнчыгышка таба 150 м көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м һәм көньяк-көнбатышка таба 150 м сәнәгать объектының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 300 м сәнәгать объекты буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м һәм төньякка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 50 м Буа – Килдураз автомобиль юлына кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 500 м шушы автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң, урман полосасын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 300 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 550 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 400 м җиләк-җимеш питомнигының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, урман полосасын кисеп үтеп, 20 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 150 м Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 50 м, төньяк-көнбатышка таба 40 м уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, көньяк-көнбатышка таба 350 м, көньяк-көнчыгышка таба 100 м, көньяк-көнбатышка таба 500 м көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, көньякка таба 550 м һәм көньяк-көнбатышка таба 1,9 км Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап 40 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Наратбаш авыл җирлеге чиге Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып Буа муниципаль районы чиге буйлап 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
21 нче кушымта

## Буа муниципаль районының «Яңа Тинчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Яңа Тинчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре

чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яңа Тинчәле авыл җирлеге Мөкерле, Иске Тинчәле, Тимбай, Янтуган авыл җирлекләре һәм Чүпрәле муниципаль районы белән чиктәш.

Яңа Тинчәле авыл җирлеге чиге Янтуган авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Тинчәле, Янтуган һәм Тимбай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Чынлы авылыннан 2,6 км төньякта урнашкан 65 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 2,7 км һәм көньякка таба 2,0 км, урман полосасын кисеп үтеп, Яңа Тинчәле, Янтуган авыл җирлекләре һәм Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Чынлы авылыннан 3,2 км көнбатышта урнашкан 66 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Тинчәле авыл җирлеге чиге Тимбай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 65 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буйлап, 50 м урман утыртмалары буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 2,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 350 м шушы инеш агымы буенча аска таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, 1,1 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м урман полосасы буйлап, 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 300 м көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Яңа Тинчәле, Тимбай һәм Мөкерле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Тинчәле авылыннан 6,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Тинчәле авыл җирлеге чиге Мөкерле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Тинчәле, Мөкерле һәм Иске Тинчәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сарсаз авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 57 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак үсемлекләре полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара,

шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 58 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Тинчәле авыл җирлеге чиге Иске Тинчәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 57 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,6 км, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Кече Борган – Яңа Тинчәле – Яңа Чынлы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м урман полосасы буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 150 м урман полосасы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Олы Тилчә елгасына кадәр, Яңа Тинчәле, Иске Тинчәле авыл җирлекләре һәм Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында Шәйморза авылыннан 2,6 км көнбатышта Олы Тилчә елгасында урнашкан 68 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Тинчәле авыл җирлеге чиге Чүпрәле муниципаль районы белән чиктәш җирдә 68 нче тоташу ноктасыннан алып Буа муниципаль районы чиге буйлап 66 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
22 нче кушымта

## Буа муниципаль районының «Яңа Чәчкап авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Яңа Чәчкап авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын

(«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яңа Чәчкап авыл җирлеге Бик-Үти, Югары Лашчы, Кайбыч, Норлат, Күл Черкене һәм Килдураз авыл җирлекләре белән чиктәш.

Яңа Чәчкап авыл җирлеге чиге Югары Лашчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Чәчкап, Югары Лашчы һәм Бик-Үти авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чуаш Аксуы авылыннан 200 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 15 м буа буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 1,7 км Яңа Чәчкап, Югары Лашчы һәм Норлат авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Аксуы авылыннан 1,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Чәчкап авыл җирлеге чиге Бик-Үти авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км һәм төньяк-көнбатышка таба 250 м буа буйлап аңа коя торган кибеп баручы инеш тамагына кадәр бара, 400 м шушы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары төньякка таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Буа – Яльчик» – Бик-Үти» – Яңа Чәчкап автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км, сазлыкны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 600 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,7 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 100 м шушы инеш агымы буенча аска таба буага кадәр уза, көнчыгышка таба 850 м шушы буа буйлап бара, 1,1 км инеш агымы буенча

аска таба Яңа Чәчкап, Бик-Үти һәм Килдураз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Әхмәт авылыннан 1,3 км төньякта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Чәчкап авыл җирлеге чиге Килдураз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча аска таба 1,7 км бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Буа – Каратун автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чигенә кадәр уза, көньякка таба 800 м автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буйлап Лашчы елгасына кадәр бара, 950 м шушы елга агымы буенча өскә таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м чокырның көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм көньякка таба 150 м уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,9 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап Яңа Чәчкап, Килдураз һәм Күл Черкене авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Лашчы тимер юл разъезды поселогыннан 1,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Чәчкап авыл җирлеге чиге Күл Черкене авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км урман полосасы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 900 м Яңа Чәчкап, Күл Черкене һәм Кайбыч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кыр Әнәлесе авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Чәчкап авыл җирлеге чиге Кайбыч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Чәчкап, Кайбыч һәм Норлат авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кыр Әнәлесе авылыннан 1,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасыннан алып төньякка таба 205 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Чәчкап авыл җирлеге чиге Норлат авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 250 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Буа – Яльчик» – Яңа Чәчкап – Кыр Тәүгелдесе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
23 нче кушымта

**Буа муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Норлат авыл җирлеге Югары Лашчы, Кайбыч, Яңа Чәчкап авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Норлат авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә Норлат, Кайбыч авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Татар Аксуы авылыннан 3,1 км көньякта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Норлат, Югары Лашчы авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Татар Аксуы авылыннан 1,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Норлат авыл җирлеге чиге Югары Лашчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Норлат, Югары Лашчы һәм Яңа Чәчкап авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Аксуы авылыннан 1,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман утыртмалары буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, чокырны, кибеп баручы инешне һәм аның текә уң ярын кисеп үтеп, көньякка таба 800 м чокыр төбеннән агучы инешкә кадәр бара, 1,3 км шушы инеш агымы буенча өскә таба 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Норлат авыл җирлеге чиге Яңа Чәчкап авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Норлат, Яңа Чәчкап һәм Кайбыч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кыр Әнәлесе авылыннан

1,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 250 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Буа – Яльчик» – Яңа Чәчкап – Кыр Тәүгелдесе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Норлат авыл җирлеге чиге Кайбыч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 750 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, Буа – Яльчик автомобиль юлына кадәр уза, көньяк-көнчыгышка таба 600 м шушы автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 3,1 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба, «Буа – Яльчик» – Яңа Чәчкап – Кыр Тәүгелдесе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 350 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 800 м, урман полосасы буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м бара, шуннан соң төньякка таба 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 450 м көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 300 м төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, ике мәртәбә буаны һәм буаның текә сул ярын кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары төньякка таба 1,4 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 14 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
24 нче кушымта

**Буа муниципаль районының «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ырынгы авыл җирлеге «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге, Алших, Югары Лашчы, Кайбыч, Татар Буасы, Мөкерле авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Ырынгы авыл җирлеге чиге Югары Лашчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ырынгы, Югары Лашчы авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Отрада авылыннан 4,0 км төньякта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап Ырынгы, Югары Лашчы һәм Мөкерле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Отрада авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ырынгы авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Ырынгы, Кайбыч авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Татар Аксуы авылыннан 4,1 км көньякта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ырынгы авыл җирлеге чиге Кайбыч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ырынгы, Кайбыч авыл җирлекләре һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Бикмураз авылыннан 2,6 км көньяк-көнбатышта Каилка елгасында урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып, Горький тимер

юлына һәм Буа – Каратун автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны һәм буа плотинасын кисеп үтеп, Каилка елгасы агымы буенча өскә таба 3,3 км буага кадәр бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м буа буйлап уза, 650 м Каилка елгасы агымы буенча өскә таба, плотинаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 150 м буа буйлап уза, 350 м Каилка елгасы агымы буенча өскә таба буага кадәр бара, Буа – Яльчик автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм буа плотинасын кисеп үтеп, көнбатышка таба 100 м буа буйлап уза, 100 м Каилка елгасы агымы буенча өскә таба бара, буа плотинасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 100 м буа буйлап уза, 2,8 км Каилка елгасы агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м канау буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, көньяк-көнбатышка таба 1,0 км һәм төньяк-көнбатышка таба 1,0 км бара, 500 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,3 км 4 нче, 3 нче урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ырынгы авыл җирлеге чиге «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Ырынгы авыл җирлеге, «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Татар Буасы авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Чурак авылыннан 1,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 100 м урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,4 км, урман полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 250 м һәм 50 м Буа – Каратун автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 2,0 км Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м җиләк-җимеш питомнигының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньякка таба, сынык сызык ясап, 750 м җиләк-җимеш питомнигы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, Горький тимер юлы тармагын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 550 м җиләк-җимеш питомнигының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка

таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, Буа – Каратун автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 300 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 900 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Каилка елгасына кадәр, 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ырынгы авыл җирлеге чиге Татар Буасы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ырынгы, Татар Буасы һәм Алших авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Теңкәш авылыннан 50 м төньякта Карлы елгасының уң ярында урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньякка таба 20 м, Карлы елгасын кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 400 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 29 нчы, 28 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 800 м 28 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 28 нче урман кварталы буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньякка таба 1,2 км, Буа – Ырынгы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнчыгышка таба 850 м уза, аннары канау буйлап көньяк-көнчыгышка таба 350 м һәм төньякка таба 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 300 м һәм төньяк-көнбатышка таба 100 м уза, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м урман полосасы буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 2,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Буа – Яльчик автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чигенә кадәр уза, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның шушы чиге буйлап 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Ырынгы авыл җирлеге чиге Алших авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ырынгы, Алших һәм Мөкерле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Отрада авылыннан 750 м төньяк-көнчыгышта Карлы елгасында урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып Карлы елгасы агымы буенча аска таба 4,9 км бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба һәм

төньяк-көнчыгышка таба 2,6 км шушы елганың сул яры буйлап бара, елганы кисеп үтә һәм аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба һәм төньяк-көнчыгышка таба 2,2 км аның уң яры буйлап уза, яңадан Карлы елгасын кисеп үтә һәм төньяк-көнчыгышка таба 100 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, 450 м күл буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 250 м Карлы елгасының элеккеге үзәне буйлап бара, 150 м шушы елга агымы буенча аска таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 30 м канау буйлап, көньяк-көнбатышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Карлы күленә кадәр бара, шуннан соң әлеге күл буйлап көньяк-көнчыгышка таба 300 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 900 м уза, аннары элеккеге үзән буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м һәм төньяк-көнбатышка таба 150 м Карлы елгасына кадәр бара, 1,7 км шушы елга агымы буенча аска таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап Карлы елгасына кадәр бара, аннары 800 м шушы елга агымы буенча аска таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак үсемлекләренең яр буе полосасын кисеп үтеп, күлгә кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 300 м күл буйлап уза, 100 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба күлгә кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгышка таба 150 м күл буйлап уза, 450 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ырынгы авыл җирлеге чиге Мөкерле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 650 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 400 м урман полосасы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
25 нче кушымта

## Буа муниципаль районының «Кырык Садак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Кырык Садак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кырык Садак авыл җирлеге Тимбай, Янтуган авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Кырык Садак авыл җирлеге чиге Янтуган авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кырык Садак, Янтуган авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Вольнистан авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта Чатказ елгасында урнашкан 62 нче тоташу ноктасыннан алып шушы елга агымы буенча аска таба 3,3 км Кырык Садак, Янтуган авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Янтуган авылыннан 1,7 км көньяк-көнбатышта Чатказ елгасында урнашкан 63 нче тоташу ноктасына кадәр бара, аннары Кырык Садак, Янтуган авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Янтуган авылыннан 150 м көнбатышта Чатказ елгасында урнашкан 64 нче тоташу ноктасыннан алып шушы елга агымы буенча аска таба 1,3 км бара, шуннан соң төньякка таба, сынык сызык ясап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 100 м зиратның көнбатыш чиге буйлап һәм төньяк-көнчыгышка таба 150 м төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, кибеп баручы инешне, юл буе урман полосаларын һәм Тимбай – Кырык Садак – Красномайск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м һәм төньякка таба 2,4 км уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 600 м канау буйлап Кырык Садак, Янтуган һәм Тимбай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ташкичү авылыннан 1,3 км төньякта урнашкан 61 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кырык Садак авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә 63 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 64 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кырык Садак авыл җирлеге чиге Тимбай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 61 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м үләт базы буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак үсемлекләре полосасын, кибеп баручы инешне, Карлы елгасын һәм аның кибеп баручы ермагын кисеп үтеп, Кырык Садак, Тимбай авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Кече Шыгырдан авылыннан 1,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 60 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кырык Садак авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасы белән чиктәш җирдә 60 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 62 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
26 нчы кушымта

## Буа муниципаль районының «Иске Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Суыксу авыл җирлеге Адав-Толымбай, Алших, Боерган, Кыят, Күшке, Карлы һәм Иске Тинчәле авыл җирлекләре белән чиктәш.

Иске Суыксу авыл җирлеге чиге Адав-Толымбай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Суыксу, Адав-Толымбай һәм Карлы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Карлы авылыннан 2,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 42 нче тота-

шу ноктасыннан алып көньякка таба 2,2 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Суыксу елгасына кадәр бара, 250 м Суыксу елгасы агымы буенча аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 250 м, көньякка таба 450 м, казылган җирләрне кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 250 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, шуннан соң көньякка таба 1,7 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап Иске Суыксу, Адав-Толымбай һәм Кыят авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Суыксу авылыннан 1,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Суыксу авыл җирлеге чиге Кыят авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 200 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,6 км шушы инеш агымы буенча өскә таба Иске Суыксу, Кыят һәм Боерган авыл җирлекләре тоташкан урында Иске Суыксу авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Суыксу авыл җирлеге чиге Боерган авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Суыксу Боерган һәм Күшке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Суыксу авылыннан 1,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 49 нчы тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 200 м, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 48 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Суыксу авыл җирлеге чиге Күшке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 49 нчы тоташу ноктасыннан алып, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 3,1 км бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Суыксу, Күшке һәм Иске Тинчәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Тинчәле авылыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Суыксу авыл җирлеге чиге Иске Тинчәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 50 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 200 м төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 450 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап, 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, текә ярны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 500 м шушы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Суыксу, Иске Тинчәле һәм Алших авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Суыксу Выселкасы авылыннан 2,9 км төньякта урнашкан 55 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Суыксу авыл җирлеге чиге Алших авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 55 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 3,7 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,4 км шушы инеш агымы буенча аска таба күлгә кадәр уза, шуннан соң көнчыгышка таба 100 м шушы күл буйлап бара, 250 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба буага кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м буаның уң яры буйлап һәм 1,2 км буа буйлап, буа плотинасын кисеп үтә, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 100 м, чокырны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 100 м, төньякка таба 150 м бара, 1,5 км урман полосасының көнбатыш чиге буйлап Иске Суыксу, Алших һәм Карлы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Суыксу авылыннан 1,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Суыксу авыл җирлеге чиге Карлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 150 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,5 км урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м уза, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аның көньяк-көнчыгыш чигенә кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 850 м автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның шушы чиге буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, 40 м 42 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
27 нче кушымта

**Буа муниципаль районының «Иске Тинчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Тинчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Тинчәле авыл җирлеге Алших, Күшке, Мөкерле, Яңа Тинчәле, Иске Суыксу, Чуаш Киштәге авыл җирлекләре, Чүпрәле муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Иске Тинчәле авыл җирлеге чиге Яңа Тинчәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Тинчәле, Яңа Тинчәле һәм Мөкерле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сарсаз авылыннан 3,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 57 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,6 км, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Кече Боерган – Яңа Тинчәле – Яңа Чынлы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м урман полосасы буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 150 м урман полосасы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Олы Тилчә елгасына кадәр, Иске Тинчәле, Яңа Тинчәле авыл җирлекләре һәм Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында Шәйморза авылыннан 2,6 км көнбатышта Олы Тилчә елгасында урнашкан 68 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Тинчәле авыл җирлеге чиге Мөкерле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Тинчәле, Мөкерле һәм Алших авыл

җирлекләре чикләре тоташкан урында Сарсаз авылыннан 3,1 км төньякта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 2,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 57 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Тинчәле авыл җирлеге чиге Алших авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 56 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 1,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 2,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Тинчәле, Алших һәм Иске Суыксу авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Суыксу Выселкасы авылыннан 2,9 км төньякта урнашкан 55 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Тинчәле авыл җирлеге чиге Иске Суыксу авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Тинчәле, Иске Суыксу һәм Күшке авыл җирлекләре чикләре тоташ-кан урында Иске Тинчәле авылыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 200 м төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 450 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, текә ярны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 500 м шушы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,2 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 55 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Тинчәле авыл җирлеге чиге Күшке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Тинчәле, Күшке һәм Чуаш Киштәге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Шәйморза авылыннан 2,5 км көнчыгышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м зиратның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлык буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Олы Тилчә елгасына кадәр бара, 1,4 км шушы елга агымы буенча аска таба уза, аннары

төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Кече Боерган – Яңа Тинчәле – Яңа Чынлы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап буага кадәр бара, төньяк-көнчыгышка таба, буаны кисеп үтеп, 250 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм төньяк-көнбатышка таба 600 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, аны кисеп үтә, аннары 1,7 км шушы инеш агымы буенча өскә таба, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Тинчәле авыл җирлеге чиге Чуаш Киштәге авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Тинчәле, Чуаш Киштәге авыл җирлекләре һәм Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында Шәйморза авылыннан 2,3 км көньякта урнашкан 69 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Тинчәле авыл җирлеге чиге Чүпрәле муниципаль районы белән чиктәш җирдә 69 нчы тоташу ноктасыннан алып Буа муниципаль районы чиге буйлап 68 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Тинчәле авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Иске Тинчәле авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге, Чүпрәле муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Таковар авылыннан 2,0 км көнбатышта урнашкан 82 нче (5б) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Иске Тинчәле авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге, Чүпрәле муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Таковар авылыннан 2,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 71 нче (5а) тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Тинчәле авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чиге Чүпрәле муниципаль районы белән чиктәш җирдә 71 нче (5а) тоташу ноктасыннан алып Буа муниципаль районы чиге буйлап 82 нче (5б) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
28 нче кушымта

**Буа муниципаль районының «Тимбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Тимбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Тимбай авыл җирлеге Мөкерле, Яңа Тинчәле, Кырык Садак, Янтуган авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Тимбай авыл җирлеге чиге Кырык Садак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Тимбай, Кырык Садак һәм Янтуган авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ташкичү авылыннан 1,3 км төньякта урнашкан 61 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м үләт базы буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куаклыклар полосасын, кибеп баручы инешне, Карлы елгасын һәм аның кушылдыгын кисеп үтеп, Тимбай, Кырык Садак авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Кече Шыгырдан авылыннан 1,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 60 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Тимбай авыл җирлеге чиге Янтуган авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 61 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,6 км, Тимбай – Кырык Садак – Красномайск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, юл буе урман полосасын, текә ярлы Чатказ елгасын, зиратны кисеп үтеп, һәм көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км инешкә кадәр бара, Вольнистан – Кыят – Яшевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 250 м шушы инеш агымы буенча өскә таба буа плотинасына кадәр уза, плотинаны кисеп үтә һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,7 км буа буйлап бара, 4,0 км инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 800 м, инешләрне берничә мәртәбә кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км Тимбай, Янтуган һәм Яңа Тинчәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Чынлы авылыннан 2,6 км төньякта урнашкан 65 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Тимбай авыл җирлеге чиге Яңа Тинчәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 65 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буйлап, 50 м урман утыртмалары буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 100 м урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 2,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 350 м шушы инеш агымы буенча аска таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, 1,1 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м урман полосасы буйлап, 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 300 м көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Тимбай, Яңа Тинчәле һәм Мөкерле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Тинчәле авылыннан 6,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Тимбай авыл җирлеге чиге Мөкерле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 58 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 900 м урман полосаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 900 м төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,5 км һәм төньякка таба 950 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 2,7 км, урман полосасын, Вольнистан – Кыят – Яшевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, кибеп баручы инешне һәм Карлы елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 250 м, Карлы елгасын ике мәртәбә кисеп үтеп, Тимбай, Мөкерле авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Ямбулат авылыннан 700 м төньяк-көнбатышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Тимбай авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасы белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 60 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
29 нчы кушымта

**Буа муниципаль районының «Күл Черкене авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Күл Черкене авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Күл Черкене авыл җирлеге Зур Фролово, Кайбыч, Түбән Наратбаш, Яңа Чәчкап һәм Килдураз авыл җирлекләре белән чиктәш.

Күл Черкене авыл җирлеге чиге Кайбыч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күл Черкене, Кайбыч һәм Яңа Чәчкап авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кыр Әнәлесе авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 450 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын кисеп үтеп, Буа – Каратун автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чигенә кадәр бара, шуннан соң көньякка таба 300 м автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның шушы чиге буйлап уза, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр, 2,6 км шушы инеш агымы буенча аска таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Буа – Каратун автомобиль юлына һәм Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 1,1 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Күл Черкене, Кайбыч һәм Түбән Наратбаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Наратбаш авылыннан 1,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Күл Черкене авыл җирлеге чиге Яңа Чәчкап авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күл Черкене, Яңа Чәчкап һәм Килдураз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Лашчы тимер юл разъезды поселогыннан 1,7 км көньяк-көнбатышта урнашкан

12 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км урман полосасы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 900 м 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күл Черкене авыл җирлеге чиге Килдураз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күл Черкене, Килдураз һәм Зур Фролово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Өчмунча авылыннан 1,6 км төньякта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба, сынык сызык ясап, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, Зөя елгасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 50 м уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,4 км шушы елганың сул яры буйлап аңа коючы кибеп баручы инеш тамагына кадәр бара, 300 м шушы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 30 м агач-куак үсемлекләре массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 20 м шушы массив буйлап бара, Буа – Килдураз автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,9 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Өчмунча – Лашчы тимер юл разъезды поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чигенә кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,6 км шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм көньякка таба 350 м көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, көньяк-көнбатышка таба 100 м, тимер юлга бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр уза, 150 м шушы инеш агымы буенча өскә таба буа плотинасына кадәр бара, плотинаны кисеп үтә һәм аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м буа буйлап, 300 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба аңа башка кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, 250 м шушы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Буа – Каратун автомобиль юлына кадәр уза, шуннан соң 450 м төньякка таба шушы автомобиль юлы буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Күл Черкене авыл җирлеге чиге Зур Фролово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Күл Черкене, Зур Фролово һәм Түбән Наратбаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Күл Черкене

авылыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта Зөя елгасында урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып Чирка елгасы агымы буенча өскә таба 3,6 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 500 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 900 м һәм көньяк-көнбатышка таба 450 м Зур Фролово – Күл Черкене автомобиль юлына кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,0 км шушы автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап күлгә кадәр уза, 100 м күл буйлап төньяк-көнбатышка таба бара, 1,8 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Күл Черкене авыл җирлеге чиге Түбән Наратбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып Зөя елгасы агымы буенча аска таба 1,6 км бара, көньяк-көнбатышка таба 40 м аңа коючы кибеп баручы инеш тамагына кадәр бара, 950 м шушы инеш агымы буенча өскә таба аның чишмә башына кадәр уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 150 м урман полосасы буйлап, 350 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары урман полосасы буйлап көньякка таба 100 м һәм көнбатышка таба 1,4 км, Буа – Килдураз автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,0 км урман полосасының төньяк чиге буйлап, 800 м урман полосасы буйлап, 50 м аның төньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
30 нчы кушымта

**Буа муниципаль районының «Килдураз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Килдураз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Килдураз авыл җирлеге Бик-Үти, Зур Фролово, Яңа Чәчкап, Күл Черкене авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы белән чиктәш.

Килдураз авыл җирлеге чиге Яңа Чәчкап авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Килдураз, Яңа Чәчкап һәм Бик-Үти авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Әхмәт авылыннан 1,3 км төньякта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча аска таба 1,7 км бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Буа — Каратун автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чигенә кадәр уза, көньякка таба 800 м автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның әлеге чиге буйлап Лашчы елгасына кадәр бара, 950 м шушы елга агымы буенча өскә таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м текә ярның көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм көньякка таба 150 м уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,9 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап Килдураз, Яңа Чәчкап һәм Күл Черкене авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Лашчы тимер юл разъезды поселогыннан 1,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Килдураз авыл җирлеге чиге Бик-Үти авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,7 км, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 2,2 км бара, чокырларны кисеп үтеп, 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньякка таба 500 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап һәм төньяк-көнбатышка таба 650 м көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Килдураз, Бик-Үти авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кабалан авылыннан 1,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Килдураз авыл җирлеге чиге Апас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып Буа муниципаль районы чиге буйлап Килдураз, Зур Фролово авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Дүртиле авылыннан 5,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Килдураз авыл җирлеге чиге Күл Черкене авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Килдураз, Күл Черкене һәм Зур Фролово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Өчмунча авы-

лыннан 1,6 км төньякта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба, сынык сызык ясап, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, Зөя елгасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 50 м уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,4 км шушы елганың сул яры буйлап аңа коючы кибеп баручы инеш тамагына кадәр бара, 300 м шушы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 30 м агач-куак үсемлекләре массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 20 м шушы массив буйлап бара, Буа — Килдураз автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,9 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Өчмунча — Лашчы тимер юл разъезды поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чигенә кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,6 км шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм көньякка таба 350 м көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, көньяк-көнбатышка таба 100 м, тимер юлга бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр уза, 150 м шушы инеш агымы буенча өскә таба буа плотинасына кадәр бара, плотинаны кисеп үтә һәм аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м буа буйлап, 300 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба аңа башка кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, 250 м шушы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Буа — Каратун автомобиль юлына кадәр уза, шуннан соң 450 м төньякка таба шушы автомобиль юлы буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Килдураз авыл җирлеге чиге Зур Фролово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 20 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Зөя елгасына кадәр бара, 20 м шушы елга буйлап һәм 700 м аның агымы буенча аска таба уза, аннары көнчыгышка таба 20 м Зөя елгасы буйлап аның уң ярына кадәр, 40 м агач-куак үсемлекләренең яр буе массивы буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 800 м урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 150 м кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр бара, 350 м шушы инеш агымы буенча аска таба аның Инеш елгасына койган җиренә кадәр уза,

2,2 км шушы елга агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 100 м канау буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 2,6 км «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 50, 51, 52 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 4,4 км 52, 53, 54, 55, 56 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, төньякка таба 1,9 км 56 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
31 нче кушымта

**Буа муниципаль районының «Чуаш Киштәге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Чуаш Киштәге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чуаш Киштәге авыл җирлеге Әлши, Күшке, Иске Тинчәле авыл җирлекләре, Чүпрәле муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Чуаш Киштәге авыл җирлеге чиге Иске Тинчәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чуаш Киштәге, Иске Тинчәле авыл җирлекләре һәм Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында Шәйморза авылыннан 2,3 км көньякта урнашкан 69 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап,

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км Чуаш Киштәге, Иске Тинчәле һәм Күшке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Шәйморза авылыннан 2,5 км көнчыгышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чуаш Киштәге авыл җирлеге чиге Күшке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Чуаш Киштәге, Күшке һәм Әлши авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чуаш Киштәге авылыннан 1,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 53 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 3,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чуаш Киштәге авыл җирлеге чиге Әлши авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 53 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 300 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 1,4 км Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына кадәр уза, көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,7 км шушы автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 2,5 км «Казан – Ульяновск» – Иске Чүпрәле автомобиль юлы буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,4 км Чуаш Киштәге – Таковар автомобиль юлы буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 2,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, урман полосасын кисеп үтеп, 40 м Чуаш Киштәге, Әлши авыл җирлекләре һәм Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында Новоселки авылыннан 1,0 км көнчыгышта урнашкан 72 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чуаш Киштәге авыл җирлеге чиге Чүпрәле муниципаль районы белән чиктәш җирдә Буа муниципаль районы чиге буйлап Чуаш Киштәге авыл җирлеге, Чүпрәле муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Таковар авылыннан 2,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 70 нче (5 нче) тоташу ноктасыннан алып 69 нчы тоташу ноктасына кадәр, шулай ук 72 нче тоташу ноктасыннан алып Чуаш Киштәге авыл

җирлеге, Чүпрәле муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Новоселки авылыннан 700 м көньяк-көнчыгышта Иске Чынлы елгасы ермагында урнашкан 78 нче (4г) тоташу ноктасына кадәр бара.

Чуаш Киштәге авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 78 нче (4г) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 70 нче (5 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Буа муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү<br>һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>32 нче кушымта

## Буа муниципаль районының «Янтуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Янтуган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Янтуган авыл җирлеге Яңа Тинчәле, Кырык Садак, Тимбай авыл җирлекләре, Чүпрәле муниципаль районы һәм Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Янтуган авыл җирлеге чиге Чүпрәле муниципаль районы белән чиктәш җирдә Янтуган, Яңа Тинчәле авыл җирлекләре һәм Чүпрәле муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Чынлы авылыннан 3,2 км көнбатышта урнашкан 66 нчы тоташу ноктасыннан алып Буа муниципаль районы чиге буйлап Янтуган авыл җирлеге, Чүпрәле муниципаль районы һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Чынлы авылыннан 3,9 км көнбатышта урнашкан 67 нче (6 нчы) тоташу ноктасына кадәр бара.

Янтуган авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасы белән чиктәш җирдә 67 нче (6 нчы) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Янтуган, Кырык Садак авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасы чикләре тоташкан урында Вольнистан авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта Чатказ елгасында урнашкан 62 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Янтуган авыл җирлеге чиге Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге белән чиктәш җирдә Янтуган, Кырык Садак авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасының басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында Янтуган авылыннан 1,7 км көньяк-көнбатышта Чатказ елгасында урнашкан 63 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Янтуган, Кырык Садак авыл җирлекләре һәм Чуваш Республикасының басу аша кишәр-леге чикләре тоташкан урында Янтуган авылыннан 150 м көнбатышта Чатказ елгасында урнашкан 64 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Янтуган авыл җирлеге чиге Кырык Садак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 62 нче тоташу ноктасыннан алып Чатказ елгасы агымы буенча өскә таба 3,3 км 63 нче тоташу ноктасына кадәр бара, аннары 64 нче тоташу ноктасыннан алып Чатказ елгасы агымы буенча аска таба 1,3 км бара, шуннан соң төньякка таба, сынык сызык ясап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 100 м зиратның көнбатыш чиге буйлап һәм төньяк-көнчыгышка таба 150 м төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң, кибеп баручы инешне, юл буе урман полосаларын һәм Тимбай – Кырык Садак – Красномайск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м һәм төньякка таба 2,4 км уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 600 м канау буйлап Янтуган, Кырык Садак һәм Тимбай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ташкичү авылыннан 1,3 км төньякта урнашкан 61 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Янтуган авыл җирлеге чиге Тимбай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 61 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,6 км, Тимбай – Кырык Садак – Красномайск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, юл буе урман полосасын, текә ярлы Чатказ елгасын, зиратны кисеп үтеп, һәм көньяк-көнчыгышка таба 1,6 км инешкә кадәр бара, Вольнистан – Кыят – Яшевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 250 м шушы инеш агымы буенча өскә таба буа плотинасына кадәр уза, плотинаны кисеп үтә һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,7 км буа буйлап бара, 4,0 км инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 800 м, инешләрне берничә мәртәбә кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км Янтуган, Тимбай һәм Яңа Тинчәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Чынлы авылыннан 2,6 км төньякта урнашкан 65 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Буа муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
33 нче кушымта

**Буа муниципаль районының «Яшевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Яшевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яшевка авыл җирлеге Кыят авыл җирлеге һәм Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш.

Яшевка авыл җирлеге чиге Кыят авыл җирлеге чиге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 750 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 64 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, көньякка таба, сынык сызык ясап, 1,2 км көнчыгыш чиге буйлап һәм төньяк-көнбатышка таба 400 м көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң 150 м 63 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, 1,6 км шушы инеш агымы буенча аска таба аның Кыят елгасына койган җиренә кадәр бара, 2,1 км шушы елга агымы буенча өскә таба аңа инеш койган тамакка кадәр уза, 1,3 км шушы инеш агымы буенча, Вольнистан – Кыят – Яшевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, өскә таба, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, агач-куак үсемлекләренең яр буе полосасын һәм текә ярны кисеп үтеп, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, чокырны кисеп үтеп, 50 м уза, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м чокыр төбеннән инешкә кадәр бара, 450 м шушы инеш агымы буенча аска таба уза, аннары көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 350 м авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап Крутайка елгасына кадәр бара, инешнең текә уң ярын кисеп үтеп, 1,6 км шушы елга агымы буенча өскә таба, буа плотинасын кисеп үтеп, аның көнчыгыш чигенә кадәр бара, төньякка таба 10 м плотинаның көнчыгыш чиге буйлап уза һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 150 м буаның уң яры буйлап, 400 м Крутайка елгасы агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, Крутайка елгасын ике мәртәбә кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км 76 нчы, 79 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м 84 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм көньяк-көнчыгышка таба 2,2 км 84 нче, 88 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Яшевка, Кыят авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яшевка авылыннан 5,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Яшевка авыл җирлеге чиге Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып Буа муниципаль районы чиге буйлап 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.».